# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 12 (688) 25 июнь 2019 ел (1440, Шәүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Файдалы кеше булыйм дисәң...



Мәктәпкә йөрүдән вә сабак укудан максат – Иман белү, тәрбияле вә камил адәм булу кирәклеген хәтерегездән чыгармагыз һәм шушы максатка ихлас белән йөрегез. “Ни өчен мәктәпкә барасыз вә ни өчен укыйсыз?” - дип сораучы булса, сез дә: “Аллаһы Тәгаләнең боерыгын җиренә җиткерү өчен, атам-анама догачы булу вә туган һәм кардәшләремә, кабиләдәшләремә вә диндәшләремә бер файдалы кеше булуны өмет итәм”, - дип җавап бирегез. Бу рәвештә җавап бирү баланың гакыллы булачагына дәлил булыр. Мәктәпләрдә дәресләрнең тәмамлануы соңында, “Инде уку вакыты үтте, гыйлемем да җитәрлек булды” , дип, гыйлемнән вә китаплардан аерылмагыз, бәлки буш вакытларыгызда һаман китапларыгызны укыгыз вә һәрбер яңа китапларны, әдәби китапларны укыгыз. Бу сәбәпле зиһенегез ачылыр, гакылыгыз артыр, фикерегез тугры булыр.

**(Риза Фәхреддин. “Әхлак гыйлеме”.)**

## Гыйлем - нур ул



Чаллының «Ак мәчет» мәдрәсәсендә белем алучылар өчен бу көннәрдә «кызу урак өсте» булды: шәкертләр курс эшләре, диплом эшләре яклады. 23 июнь көнне исә мәдрәсәне тәмамлаучыларга дипломнар тапшырылды. Әлеге тантаналы кичәдә мәдрәсә директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча мөфти киңәшчесе Равил хәзрәт Зөфәров, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин катнашып, үзләренең котлау сүзләрен, ихлас теләкләрен җиткерделәр.



Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында өлкән яшьтәгеләр дә, параллель рәвештә дөньяви уку йортларында укучы яшьләр дә, табиб, укытучы, инженер кебек төрле һөнәр ияләре дә бар. Алар барысы да “Ак мәчет” мәдрәсәсе мөгаллимнәренә эчкерсез рәхмәт белдерделәр.

Яңа уку елында да мәдрәсә үзендә дини белем алырга теләүчеләрне көтеп кала. Биредә торып уку 2 ел да 10 ай, кичке мәдрәсәдә уку 3 ел да ун ай, читтән торып уку 3 ел да ун айга тәгаенләнгән.

## Яшьләр дә Болгарга җыела



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның мөселман дин әһелләре белән Болгарда узган очрашуы кысаларында балалар һәм яшьләр өчен Бөтенроссия рухи-мәгариф лагере оештыру тәкъдиме яңгырады. Хәзерге вакытка 12-19 июль көннәрендә Болгар музей музей-тыюлыгы территориясендә урнашкан палаткалы шәһәрчектә узачак VIII Мөселман яшьләре форумында катнашу өчен Россиянең һәм дөньяның төрле почмакларыннан – Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртия, Мордовия республикаларыннан, Оренбург, Чиләбе, Свердловск, Самара, Төмән өлкәләреннән, Ямал-Ненец автономияле округыннан, Мәскәүдән, шулай ук Казакстаннан барлыгы 140тан артык гариза кабул ителгән. Искәртеп үтик: җыенда катнашуга 18 яшьтән алып 30 яшькәчә 200 кеше чакырыла. Гаризалар 2019 елның 7 июленә кадәр кабул ителә. Мөселман яшьләре форумы – егетләр һәм кызлар өчен дини белемнәрне тирәнәйтү, камилләшү, мөселман социаль проектлары өстендә эшләү һәм аларны тәкъдим итү мәйданчыгы. Быел чара Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Тәфсир елына багышлана. Өммәтебезнең иң сәләтле, актив һәм өметле вәкилләрен туплаячак бу җыен кысаларында лекцияләр, дәресләр, дөньякүләм танылган шәхесләр белән очрашулар оештыру каралган.

## Болгар җирендә



15 июньдә “Изге Болгар җыены” узды, анда Россиянең төрле төбәкләреннән күпсанлы мөселманнар, Татарстан Республикасы җитәкчелеге, дин әһелләре һ.б. кунаклар катнашты.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, соңгы 10 елда борынгы Болгар җирлегендә бик зур үзгәрешләр булды. “Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә, бу җирдә искиткеч туристик үзәк булдырып, бөек тарихи мирасны торгызуга ирешкәннәр”, - дип билгеләп үтте ул. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чиратында чарада катнашучыларга Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең хәдисе белән мөрәҗәгать итте: “Биш нәрсә килгәнче биш төрле әйбернең кадерен бел: картлык килгәнче яшьлекнең, авыру-сырхау килгәнче сәламәтлекнең, фәкыйрьлек килгәнче байлыкның, мәшәкатьлек килгәнче буш вакытның, үлем килгәнче яшәүнең”.

Әлеге чараның күркәм бер мизгеле - Җәмигъ мәчете территориясендә җәмәгать белән өйлә намазы уку булды.

## Буада бәйрәм



Буа районы Кайбыч авылы мәчетенә 25 ел тулу уңаеннан тантаналы чара узды. Чарада район имам-мөхтәсибе Илмир хәзрәт Хәсәнов һәм башка кунаклар катнашты. Авыл имамы Назыйм хәзрәт Фәхретдинов кыскача мәчет тарихын сөйләп үтте. Илмир хәзрәт үзенең вәгазендә һәрдаим мәчеткә йөреп, гамәл-гыйбадәт кылып яшәргә, мәхәлләне әйдәп барырга кирәклегенә басым ясады, бүгенге көндә мәхәлләгә булышып торучыларга мөхтәсибәт исеменнән рәхмәт хатлары, бүләкләр тапшырды. Авылны хөрмәт итеп кайтучы кунаклар үзләренең җылы тәбрик сүзләрен ирештерделәр. Кайбыч авылы үзидарәсе рәисе Габдрахманов Нияз Шакир улы килгән хәзрәтләргә авыл исеменнән рәхмәтен җиткерде. Бәйрәм авыл мәдәният сараенда әзерләнгән мул табын артында дәвам итте.

## Җәйге яллар җитте

Чаллының «Ихлас» мәчетендә өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә файдалы чаралар еш булып тора. Быел да, балаларның җәйге ялларын файдалы һәм кызыклы итеп уздыру максатыннан, 8 яшьтән 14 яшькә хәтле малайлар өчен җәйге рухи-сәламәтләндерү курслары оештырыла. Программада Коръән, иман, әдәп дәресләре, конкурслар, мастер-класслар, поход каралган. Түләү мәсьәләсендә күп балалы һәм матди яктан авырлыклары булган гаиләләргә аерым ташлама бар.

# Күңел төшенкелеге

**Мөхәммәд хәзрәт МӨХӘММӘТОВ,**
**Чаллының Җәмигъ мәчете имамы,**
**"Ак мәчет" мәдрәсәсе мөгаллиме.**

Беренче буын мөселманнар, бигрәк тә сәхәбәләр турында сөйләгәндә без бик күп гыйбрәтләр алабыз. Чөнки алар "Раббым – Аллаһ" дигән өчен генә йортларыннан куылдылар, үтерелделәр, бик күп сынаулар аша уздылар. Һәм шуның белән беррәттән шушы сынаулар, белүебезчә, аларны ныгытып кына барды. Аллаһы Тәгалә Коръәндә менә бу дөньяга килгән сынауларны күбек белән чагыштырып болай ди: "...күбеккә килгәндә, ул барча файдасыз әйберләр кебек үк бетәр. Әмма кешеләргә файда китерүче әйбер җирдә калыр" (13:17).

Көчле агым булганда су өстенә күбек җыела. Менә шушы күбек күпме генә җыелса да, иртәме-соңмы юкка чыгачак. Һәрбер файдасыз әйбер юкка чыгачак, мәгәр кешеләргә файда китерүче әйбер җирдә кала дип Аллаһы Раббыбыз безгә аңлата. Аллаһы Илчесе һәм аның сәхәбәләре килгән сынауларны җиңел итеп кабул иткәннәр, пошаманга төшмәгәннәр. Чөнки алар бу дөньядагы бөтен әйбернең Аллаһы Тәгаләдән икәнен белгәннәр. Ниндидер эшкә килеп терәлгәч зарлану - булган хәлең, алып торган урының, эшләгән эшең белән риза булмавыңны аңлата. Ә дөреслектә һәрбер мөэмин-мөселман һәрбер әйбернең Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә ышана. Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, белгән: һәрбер хәлне, эшне, әгәр дә яхшы гына тырышкан очракта, уңай якка хәл итеп булачагын. Һәм ул еш кына Аллаһның ошбу сүзләрен кабатлый торган булган: "Минем колымның хәле - Минем турында уйлаганча. Ул Минем турында яхшы фикердә булса, Мин аңа яхшылык кылырмын. Әгәр ул Минем турында начар фикердә булса, Мин аңа да шундый мөгамәлә кылырмын" (Кодси хәдис). Һәм икенче, без еш кабатлый торган хәдис: "Мөселман кешенең хәле гаҗәптер. Аның һәр хәле үзе өчен хәерледер. Үзенчәлекләр аңа гына хас. Әгәр яхшылык килсә, ул шөкер итә. Әгәр сынау килсә, сабыр итә, ул да аңа яхшылык була – хәерлелек булып языла".

Бу хәдистә пәйгамбәребез (с.г.в.) мөселманнарга килә торган бөтен хәлнең дә инде яхшы, хәерле икәнен аңлата. Һәрбер кеше үзенә килгән изгелекне дә, сынауларны да ризалык белән кабул итәргә тиешлекне безгә җиткерә. Шушы карашын сәхәбәләрендә дә булдыры. Әнәс ибн Мәлик хәбәр иткәнчә, Аллаһ илчесе әйткән: "Уңышсызлык дигән төшенчә юк. Мин барсын да яхшыга юрауны өстен күрәм". Һәм сәхәбәләр шушы яхшыга юрау –тәфәүәл нәрсә соң ул дип сорагач, ул әйтте: "Бу матур, яхшы сүз",– дип.

Беләбез ки - бу дөньяда вакыйгалар бер-берсен бик ашыктырып килә: килгән сөенечне күңел төшенкелеге алыштырырга, күңелең төшеп китсә, алмашка сөенеч тә килергә мөмкин. Кайбер кеше зарлана, "уңышсызлыклар килә башлады", дип. Сәхәбәләр вакытында да кайвакыт мондый сөйләшүләр булган. Мәсәлән, Гурва ибн Гамир искә төшергәнчә, Аллаһ илчесе янында булганда, бервакыт сәхәбәләр уңышсызлык турында сөйләшкәннәр һәм Аллаһ илчесе аларга мондый киңәш биргән: "Иң яхшысы - бөтен әйберне дә яхшыга юрау. Уңышсызлык кебек төшенчә мөселманнарны хәрәкәт итүдән, гамәл кылудан тыймасын! Әгәр берәр кеше күңелсез әйбер күрсә: "Әй Аллаһ, Син генә яхшылык кыласың һәм Син генә кайгы-хәсрәтне ерагайта аласың! Синең сәбәпле генә бездә гөнаһка кермәскә көч-куәт бар, һәм Синең сәбәпле генә бездә гыйбадәт кылырга көч бар!" – дисен," – ди.

Без алдагы хәдистән күрәбез: кешегә килгән сынаулар вакытында пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, бөтен кешене дә Аллаһы Тәгалә белән элемтәне яхшыртырга өндәде. Килгән сынауларда да мөселман кеше Раббысына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, Таиф шәһәреннән ташлар ыргытып куып чыгарылгач, иң беренче Раббысына мөрәҗәгать итте һәм Аллаһы Тәгалә озак та көттермичә аңа җавап җибәрде. Аллаһ илчесе, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, бөтен әйберне үзеннән күрә иде. Хәтта шул уңышсызлыкларга ирешүенең сәбәбен үзеннән күрде, "бәлки үземдә җитешсезлек бардыр" дип борчылды. Һәм Аллаһы Тәгалә аңа "Әнгам" сүрәсенең 33 аятендә җавап бирә: "Әй Мөхәммәд, алар сине ялганга чыгармыйлар, ләкин бу залимнәр Аллаһының аятьләрен ялганга чыгаралар", - дип.

Алдагы хәдистән без бөтен әйбернең Аллаһтан икәнлеген танырга тиеш булуын күрәбез. Һәм Аллаһ сәбәпле генә безнең сәҗдә кылырга, Аллаһны тыңларга, гөнаһларга кермәскә көч-куәт барлыгын Аллаһ Илчесе ассызыклый. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә без хәрамнән тыела алабыз, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә без Аллаһы Раббыбызны таный алабыз, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә без намазларыбызны торгызабыз һәм башка изгелекләрне эшли алабыз.

Кайвакытта кешеләр бертуктаусыз искән җилләрне, яуган яңгырларны, гарасатларны ләгънәт кыла башларга мөмкин. Ләкин Аллаһ илчесе көчле яңгыр, көчле җил яки шуңа охшаш көнторышы булганда, аларны ләгънәт кылырга түгеллеген, һәрдаим дога кылырга кирәклеген киңәш итә торган булган. Җил чыкса - шуның начарлыгыннан, шуның зыяныннан Аллаһыга сыена торган булган.

Аллаһ Илчесенең бөтен әйберне дә яхшыга юрарга өндәве бик үтемле тәрбия чарасы булып тора. Алдан ук ул кешеләрне яхшылыкка әзерли торган булган. Һәм шуның бер мисалы: Ходайбия килешүен төзү алдыннан Госман, аннан Аллаһ разый булсын, китеп бара Мәккә мөшрикләре ягына. Мәккә мөшрикләре ягыннан Сухәел ибн Гамр килә. Ул пәйгамбәребезгә, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, бик күп начарлыклар эшләгән кеше, аны хурлап шигырьләр язучы. Һәм, әлбәттә, сәхәбәләр аны яратып бетерми торган булалар. Хәтта вакытында Гомәр (р.г): "Әйдә, мин аның тешен бәреп төшерәм, тешен төшергәч сүзне матур итеп сөйли алмас,"- ди. Менә шушы Сухәел килгәндә пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, сәхәбәләрне алдан ук әзерләп куя: "Сезнең эшләрегез хәзер җиңеләер", - ди. "Сәхел" – гарәп телендә җиңеллек дигәнне аңлата. "Сухәел" шуның җиңеләйтелгән формасы. Сухәел бик яхшы сәясәтче, башлы кеше була. Аллаһ илчесенең хәлләрне яхшы якка юравы "тәфәүл" дип атала, ягъни яхшылыкка юрау, һәрбер әйбер турында да яхшы фикердә булу. Өметсезлекне Аллаһ илчесе тыя торган булган. Чөнки кешене күңел төшенкелеге биләп алса, ул ялкаулана һәм ахыр чиктә чынлап та уңышсызлыкка ирешергә мөмкин. Ялкауланган, күңел төшенкелеге биләп алган хәлдә, бөтенебезгә дә билгеле, кешенең бер эшкә дә кулы күтәрелми. Хәтта гадәтләнгән, көндәлек эшләрдә дә ниндидер авырлык сизә башлый. Тырышмаган очракта нәтиҗәсе дә начар була бит. Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, шушы әйберне тыя торган булган. Алда әйтелгәнчә, тәфәүл – яхшылыкка юрауның, яхшы дип уйлауның асылында, пәйгамбәребез әйтеп калдырганча, Аллаһ турында күркәм, яхшы фикердә булу ята. Чөнки ул Раббысының аңа карата яхшы мөгамәләдә булуына ышана, өметләнә, Раббысы аны бервакытта да ярдәмсез калдырмас дип инана.

Безнең халкыбызда да төш юрау дигән әйбер бар бит: тегене күрдем, моны күрдем ди. Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, төшләрне дә яхшы якка юрый торган булган. Бервакыт Үмм Фәдл, аннан Аллаһ разый булсын, – пәйгамбәребезнең җингәсе (абыйсы Габбасның хатыны) Аллаһы рәсүленә килә һәм болай ди: "Әй Аллаһ илчесе! Мин синең турыңда бик начар төш күрдем – синең бер кисәк итеңне кисеп алдылар һәм минем йортыма кертеп куйдылар". Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, әйтә: "Син бик яхшы төш күргәнсең. Чынлыкта минем кызым Фатыйма ул табачак һәм синең улың Кусамәнең сөтен аңа бирерләр, син аның сөт анасы булырсың", - ди. Чынлап та озак вакыт үтми – Фатыйма, аннан Аллаһ разый булсын, ир бала – Хөсәенне таба һәм Үмм Фәдл, аннан Аллаһ разый булсын, аның сөт анасына әверелә.

Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, төшләрне юрау буенча түбәндәгеләрне әйтеп калдырган: төшләр өч төрле була. Беренчеләре – Аллаһ тарафыннан булганнары яхшылыкны хәбәр итә; икенчеләре – көндәлек борчуларны һәм вакыйгаларның агышын чагылдыра; өченчеләре – куркыта торган төшләр, аларны шайтан кеше күңеленә кертергә тырыша. Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм бәрәкәтләре булсын, әйтә: "Яхшы төшне кешегә сөйләсәгез була. Начар төш күрсәгез берәүгә дә сөйләмичә намаз укыгыз", - ди.

Кеше Аллаһы Тәгалә турында яхшы фикердә булса аның күңелендә дә изгелек була, аңа изге гамәл кылу җиңеләйтелә. Ул тирә-юнь өчен изгелек чыганагына әверелә. Раббыбыз Аллаһ турында фикерләребез гел яхшы булса иде.

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Бәрәкәтле адәм шул кешедер: сүзенә караганда эше күп вә тышына караганда эче яхшы

* Дөньяда иң авыр нәрсә — ризык аз вә гакыл күп булып, икесе бергә җыелудыр

* Җиңел саналган эшләрнең ахырлары күп вакытта — авыр вә авыр күрелгән эшләрнең соңлары күп вакытта җиңел буладыр

* Ачу килү изгелекләрне онyттыра

* Тиешле булмаган кешене мактау вә яманлау — сазлыкка өй салу мисалында

* Күңелне үзенә тартучы нәрсә — кешенең яхшы холкы белән яхшы гадәтләредер

* Сүзләрнең кыйммәтлесе — заман үтү белән онытылмый торганы

* Кеше үзенең хатасын заманага йөкләтә

* Хәзерлекләре булган кешеләр куркынычлы эшләргә дә каршы торалар

* Төшүе авыр булырлык югары урынга менәргә кызыкма

* Өмет бетү куркакны да батырландыра

* Дошманны җиңү өчен иң көчле корал — аңа изгелек итү

**Риза ФӘХРЕДДИН**

## СОРАУ-ҖАВАП

***Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.***

**Сорау.** 1) Тәһарәтнең фарызы һәм сөннәте бар. Кайсы вакытта тутырып тәһарәт алырга мөмкинчелек булмый (истинҗә кылырга, аякны юарга), шундый чакларда тәһарәтнең фарызын гына башкарырга ярыймы?

2) Тәсбих намазын башкарганда ике рәкагатьтән соң ярты әттәхият укырга кирәкме, әллә укымасаң да ярыймы?

**Винер хаҗи Мирхәйдәров, Уфа шәһәре.**

**Җавап.** 1) Тәһарәтнең фарызлары дүртәү: бер кат битне юу, бер кат ике кулны терсәкләрне кертеп юу, башның дүрттән бер өлешенә мәсех кылу, бер кат аякларны ашыйк сөякләрен кертеп юу. Шушы 4 фарыз үтәлсә генә тәһарәт дөрес була. Шулай итеп аякларыгызны юмасагыз, тәһарәтегез дөрес булмый. Мәгәр читек кигән булсагыз, аякларны юмыйча читекләргә мәсех кылу дөрес була.

2) Беренчедән, Әбү Хәнифә буенча, тәсбих намазын уку дөрес түгел, ул намаз мәнсух кылынган (баштa булган, соңыннан бетерелгән). Икенчедән, нәфел намазлары сөннәт намазлары кебек укылалар. Ягъни, 4 яки 6, 8 рәкагатьле нәфел намазы укырга теләсәң, һәр ике рәкагатьтән соң «әттәхият»не генә укыйсың, соңгы кагъдәдә генә «салават»ны һәм «раббәнә»не кушып укыйсың.

# Ләүхел-мәхфүз

“Ләүхел-мәхфүз” гыйбарәсенең гарәп телендәге турыдан-туры мәгънәсе - саклана торган китап. Гакыйдә фәнендә “Ләүхел-мәхфүз” төшенчәсе “күктә саклана торган тәкъдир язуы” буларак аңлатыла. Галәм һәм анда булган барлык мәхлукат белән бу дөнья яралтылганнан алып беткәнчегә кадәр нәрсә булачагын теркәгән Аллаһы Тәгаләнең күктәге язуы барлыгына һәрбер мөселман ышанырга тиеш. Шулай итеп, тәкъдир кылынган барлык нәрсәләр күктә саклана торган тәкъдир язуында - “Ләүхел-мәхфүз”дә язылган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Аллаһы Тәгалә күкләрне һәм җирне бар иткәнче 50 мең ел алдан кешеләрнең язмышларын язып куйган”. “Хәдид” сүрәсенең 22-23 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә: “Ләүхел-мәхфүздә (күк китабында) язылмыйча, ягъни Аллаһ тәкъдир итмичә, җиргә дә, сезнең күңелләрегезгә дә бернинди бәла-каза, кайгы ирешмәс. Бу бәла-казаның булачагын белү Аллаһ өчен бик җиңелдер”.

Ләүхел-мәхфүзгә һәм Аллаһ әмере буенча барлык нәрсәләрне шунда язып куйган Каләмгә ышану Тәкъдиргә иман китерүнең аерылгысыз бер өлеше булып санала.

Коръәндәге кайбер дәлилләр: “Та Һа”, 20:51-52; “Хаҗ”, 22:70; “Мәләикә/Фәрештәләр”, 35:11; “Йәсин”, 36:12.

*Безгә язалар*

# Изгелек чишмәсе саекмасын



Кукмара шәһәренең Туеш мәхәлләсе мәчете ачылганга быел май аенда бер ел булды. Моңарчы бу җирлектә әле совет чорында салынган, авыл йортын хәтерләткән җыйнак кына кечкенә бина мәчет ролен үтәгән. Соңгы елларда исә мәхәллә шактый зурайды, шуңа күрә биредә яшәүчеләр замана таләпләренә җавап бирердәй яңа мәчет салырга кирәк дигән фикергә киләләр. Өлкән яшьтәге элекке имам авырып китеп вазифасын башкармый башлагач, мәхәллә халкы шушы төбәктә туып үскән, Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме булып эшләгән Айрат хәзрәт Шәфигуллинны бертавыштан имам итеп сайлый. Шуннан соң үзе дә бик оста ташчы булган Айрат хәзрәт төзелеш эшләре белән идарә итүне тулысынча үз кулына ала. Аның булганлыгыннан битәр, ихлас иманы бәрабәренәдер, Аллаһы Тәгалә барлык эшләрен уң итә, вакытында тиешле кешеләрен җибәреп тә, бер уйламаган җирдән акча һәм төзелеш материалларын юнәттереп тә, яңа мәчетнең шактый тиз арада төзелеп бетүен насыйп итә. Мәчет бинасының ачылу тантанасы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында 2018 елның 23 маенда була. Ел ярым дәвамында үзен аямыйча армый-талмый “чапкан”, бөтен җаны-тәне белән бирелеп, төзелеш мәсьәләләрен хәл итеп, эш нәтиҗәсе өчен ихлас тырышып йөргән Айрат хәзрәт мәчетнең ачылу тантанасында, күңеле тулып, әйтәсе сүзләрен әйтеп бетерә алмаса да, барлык ярдәм итүчеләргә дә бүләкләр һәм Рәхмәт хатлары тапшыра.

Әйе, шушы матур, мәһабәт бина төзелсен өчен шактый күп кеше хезмәт иткән. Шулай да, эшнең башында яхшы оештыручы булмаса, мондый нәтиҗәгә, мөгаен, ирешеп тә булмас иде: Айрат хәзрәткә хас булган тырышлыкны, сабырлыкны, җаваплылык хисен, шулай ук аның булдыклы, оста, акыллы җитәкче булуын да Аллаһы Тәгалә тиешенчә бәяләп, эш ахырын шулай хәерле кылгандыр, шәт... Мөфтиебез Камил хәзрәт үз чыгышында шушы изге эштә катнашучыларның һәммәсенә дә рәхмәтен белдереп, Туеш мәчете киләчәктә гыйбадәт кылу урыны гына түгел, дини гыйлем алу, мөселманнарны берләштереп, күңелләрне камилләштерү, күркәм әдәп-әхлакка өйрәнү үзәге булып та хезмәт итүен теләгән иде. Күрәмсең, догасы фәрештәләрнең “әмин” дигән сүзенә туры килгәндер: Айрат хәзрәт җитәкчелегендә мәхәллә активы шактый әһәмиятле һәм кирәкле эшләр оештырып җибәрде...

Әлбәттә, имамның төп вазифасы – мәчеттә биш вакыт намазның үз вакытында җәмәгать белән укылуын кайгыртудыр. Бу мәсьәләдә биредәге җәмәгатькә тел-теш тидерерлек түгел, чөнки көн саен, намаз вакытларын күрсәтүче тәкъвимнәрдә күрсәтелгәнчә, мәхәллә моңлы азан тавышына күмелә, һәрбер намаз аз дигәндә 15-20 кеше катнашында уза. Ә инде Җомга көнне Туеш мәчетенә шушы тирәдә яшәүчеләр генә түгел, башка мәхәлләләрдән дә килергә тырышалар. Сәбәбе – Коръән һәм хәдисләргә таянып, милли традицияләребез рухында төзек татар телендә сөйләнгән тирән эчтәлекле, үтемле вәгазь ишетү мөмкинлеге булудадыр. Бирегә килүчеләр Айрат хәзрәтнең нур балкып торган йөзен, тыныч, талгын сөйләмен, хикмәт белән сугарылган хикәятләрен дә күңел аша үткәреп үз итәдер.

Вәгазь дигәннән, Айрат хәзрәт Җомга вәгазьләре белән генә чикләнми: махсус билгеләнгән вакытларда, гадәттә, кичке сәгатьләрдә, күңеленә рухи азык алып иманын ныгытырга теләүчеләр янә бу мәчеткә җыйнала. Гомумән, биредә вәгазь-нәсыйхәт һәм гыйлем бирү эше бик югары дәрәҗәдә оештырылган: иртән дә, көндез һәм кичен дә, олысы-кечесе дигәндәй, мәчеттә үткәрелә торган дәресләргә төркемнәргә бүленеп атна дәвамында бик теләп йөри. Биредә сабак бирүче мөгаллимнәрнең укыту ысуллары белем алырга килүчеләрнең яшенә карап тәгаенләнә. Әйтик, уку елы дәвамында белем-тәрбия алган мәктәпкәчә яшьтәге 45 бала өчен дәресләр уен формасында оештырылды. Пенсия яшендәге өлкәннәрнең күңелләренә дә остазлар йомшак вә итагатьле итеп ачкыч таптылар. Дәресләрдә балалар белән олыларның гына түгел, яшьләрнең дә күпләп катнашуы сөендерә. Әйтергә кирәк ки, бу мәчеттә яшьләр намазга йөрүчеләрнең күпчелеген тәшкил итә, һәм шунысы мөһим – болар мәзһәбебезне, милли гореф-гадәтләребезне, телебезне хөрмәт итүче яңа буын мөселман егетләре (мәчеттә түбәтәй-кәләпүшсез бер генә егетнең булмавы да моның ачык күрсәткече). Шушы яшьләрнең милли үзаңлы, халкыбыз телен, мәдәниятен хөрмәт итүче, итагатьле, тәүфыйклы, тыныч холыклы булып тәрбияләнүендә Айрат хәзрәтнең дә саллы гына өлеше бар.

Изге Рамазан аенда Туеш мәхәлләсендә яшәүче мөселманнар бердәм вә тату җәмәгать булып ифтар мәҗлесләренә тупланды. Мәчет белән янәшә урнаштырылган җәйге чатырда көн саен сиксәнләп ураза тотучы авыз ачты. Ә төннәрен, мәчетнең ике катын да тутырып, халык, көйле зикерләргә бүленә-бүленә, тәравих намазларын укыды. Рамазанның ахыргы ун көнендә игътикәфкә калучылар бергәләп сәхәр ашады, көндезләрен исә Коръән-Кәримне хәтем кылды. Мәчеткә килүчеләргә шушы мөбарәк көннәрнең бәрәкәтен тоярга ярдәм итүдә, фазыйләтле чорның илаһилыгы белән нурландырылган күңелләрне шатландырып торуда җәмәгатьнең җаны булып саналган имамның роле бик зурдыр.

Ураза гаете көнне мәчет әйләнәсендәге мәйданчыкта балалар өчен кызыклы бәйрәм чарасы үткәрелде: биредә сабантуе мисалында төрле уеннар, конкурслар оештырылды, сабыйларга күчтәнәчләр, бүләкләр тапшырылды, тәмле пылау пешерелеп өләшенде, гает коймаклары әзерләнде. Балалар белән эшләү мәхәллә эшчәнлегендә мөһим юнәлешләрнең берсе булып санала: биредә уку елы дәвамында ислам нигезләре белән таныштырудан тыш, төрле кызыклы чаралар оештырыла.

Шунысы да игътибарга лаектыр: Айрат хәзрәт үзе җитәкләгән мәхәлләнең эшчәнлеген социаль челтәрләрдә актив яктырта. Барлык әһәмиятле чаралар фото-видеога төшерелеп, халыкка тәкъдим ителә, Туеш мәчете сурәте белән эшләнгән дивар календаре һәм буклетлар мәхәллә оештырган чараларда катнашучыларга тапшырыла, гомумән, бүләккә дә күп таратыла. Ни дисәң дә, хәзерге заманда бу үз оешмаңны, эшчәнлегеңне танытуның бер үтемле ысулы бит...

Шактый актив тормыш рәвеше алып барып, бик күп эшләр башкарырга туры килсә дә, Айрат хәзрәт гыйлемен арттыру мәсьәләсен дә даими күз уңында тота. Кукмара мәдрәсәсен һәм Казандагы “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен инде тәмамлауга карамастан, ул читтән торып Россия ислам институтының теология факультетында да белем алырга җаен табып, шушы көннәрдә диплом якларга ниятләп тора. Барысына да ничек өлгерә икән дип хәйран калабыз кайчак... Ул бит әле 4 балалы гаилә өчен җавап бирүче әти дә: тормыш иптәше Чулпан белән ике кыз һәм ике малай үстерә алар.

...Әйләнә-тирәгә гыйлем-мәгърифәт таратып, нур чәчеп торган Туеш мәчете янындарак чишмә агып тора. “Диплом яклап кайткач, мәхәллә чишмәсен төзекләндерергә уйлап торабыз. Матур итеп бизәлгән корылма төзеп, халыкка шуның ямен һәм чишмә суының түмен тоярдай бер күркәм урын булдырасы килә”, – ди Айрат хәзрәт. Имам әйтүенчә, кеше яшәгән җирлектә чиста су булуы ул – Аллаһның бик зур рәхмәте. Ләкин әлеге су чыганагын кеше кайгыртмаса, ваемсызлык күрсәтсә, Аллаһы Тәгалә аны юк итәргә дә мөмкин. Фикерләрен дәвам итеп, хәзрәт тагын болай диде: “Уйлап карасаң, дин дә чишмә кебек. Аның чисталыгын, кирәклеген, файдасын шушы рухи чыганакка битараф булмаган, тормышын шуңа бәйләп яшәргә тырышкан кеше генә аңлый һәм тоя ала. Халык үзе яшәгән җирлектәге чишмәне карап, төзекләндереп тормаса, ул чишмә бетәчәк. Дин белән дә шулай. Коръәндә бу хакта шулай диелгән: “Әгәр Аллаһка итагать итүдән йөз чөерсәгез, Ул Үз динен сездән алып башка халыкка бирер (һәм сез һәлак булырсыз...). Чиста судан башка яшәп булмаган кебек, дин тотмыйча яшәү дә – чын, хакыйкый тормыш түгел. Менә шуны мөмкин кадәр күбрәк кешегә җиткерәсе, аңлатасы килә”...

Насыйп булсын, әмин, насыйп булсын... Иншә Аллаһ, 43 яшьлек хәзрәтебезне алда иман нуры белән яктыртылган олы вә мәгънәле тормыш юлы көтә. Аның күңелендәге изгелек чишмәсе саекмасын, дин юлындагы хезмәтен Аллаһ Раббыбыз нәтиҗәле, бәрәкәтле кылсын, Үзенең олуг ярдәменнән ташламасын...

**Ришат Курамшин,**
**Кукмара.**

**ӘДӘБИ СҮЗ**

# Җомга

*Кояшлы иртәләр теләп*
*Туды җомга көне!*
*Шатлыкка, җырга, бәхеткә*
*Тулы җомга көне!*
*Һәркемне илтә мәчеткә*
*Туры җомга көне.*
*Кояш балкый, ләкин аның*
*Нуры – җомга көне!*
*Башка атна көннәреннән*
*Олы җомга көне!*
*Күп көннәр туар, аларның*
*Соңы җомга көне!*
*Күңелгә сөенеч өстәп*
*Туды җомга көне!*

***

*— Хәлең ничек, дустым?*
*Чирлим, дисең?*
*Шифа бирсен сиңа бер Алла.*
*Гыйбадәткә бергә барырбыз бер*
*Икебез дә исән булганда.*
*— Хәлең ничек, дустым?*
*Эшлим, дисең?*
*Мөмкинлек юк димсең барырга?*
*Насыйп була күрсен һәммәбезгә*
*Лаеклы ял алып калырга.*
*— Хәлең ничек дустым?*
*Вакыт юкмы?*
*Ни булды соң сиңа, әйт әле?*
*Күргәнем юк димсең пәйгамбәрне,*
*Күргәнем юк димсең Мәккәне?*
*— Хәлең ничек, дустым?*
*Барабызмы?*
*Соңга калмыйк бүген җомгага.*
*Гыйбадәткә бергә барыйк әле*
*Барыбыз да исән булганда!*

**Рифат СӘЛАХ.**

# Узып барышлый

Һәркөнне эшкә барганда мәчет янынннан узам. Манара-чалмасы күккә тигән яшел түбәле мәчет сәлам биреп кала. Кулымны каш өстенә куеп, өскә карыйм. Көмеш ае җиһанның бөтен нурларын үзендә туплап, мәһабәт кенә күктә эленеп тора кебек. «Сөбхан Аллаһ!» – дип кабатлыйм. «Шулай шул! Бигрәкләр дә матур бит, кызым! Әссәләмүгаләйкүм», – дип, эчтән генә кабатланган кебек тоелган сүзләремә җавап алам. Каршыма туктаган, ак сакаллы, ил картының сәламенә: «Вәгаләйкүмәссәлам», – дип җавап кайтарам. Тормышның үзе белән чаларган бабай сүзен дәвам итеп:

– Нишләп торасың болай, балам, әйдә узыйк, мәчет ишекләре һәрвакыт ачык. Керик, кызым, – дип мәчеткә чакыра.

– Юк, әле, бабакай, эшкә ашыгам, ничек булса да бер бушагач керермен әле, мин ерак тормыйм, – дип, юлымны дәвам итмәкче булам. Бабаем, самими елмаюын киметмичә:

– Дөньяныкы мәшәкатьләрәк шул, алай да вакыт тап әле син, – дип мәчеткә юнәлә.

Инде ничә еллар шул мәчет янынннан узам. Иртәнге намазга азан тавышына уянам. Күптәннән намазга бассам да, нишләптер мәчеткә керергә вакыт табылмый. Дөньяныкы мәшәкатьле, гел йөгердә. Өй, эш, авыл. Авыл, өй, эш. Мәчеттә озак тукталырга вакыт юк, хәер-сәдакасын салам да чыгып китәм.

Бүген ничектер, эштән кайтуынча керергә чыгарга кирәк. Эчсереңне бушатырлык хәсрәтең булганда гына мәчет ишеген тотарга түгелдер иң. Булганына шөкер итәр өчен дә, күңел тутыкмасын, әз генә дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, берәз уйланып утыру өчен дә кереп утырсаң ярыйдыр инде ул мәчеткә.

Көне буе мәктәптә балалар тавышыннан колак тона. Иртәдән балалар каршына басып, сөйләп тору телне дә, кайчак җанны да арыта. Ничектер аерым гына каласы килә, сөйләшмичә генә торасы килә. Укыту мәшәкатьләрен читкә куеп, тын гына утырасы килә. Шул уйларымнан, дәфтәрләремне сумкама тутырып, мәктәптән чыгам. Бер сумка дәфтәрне әле бер кулыма, әле икенче кулыма алыштырып, кайтыр юлдан атлыйм. Бүген иртә белән озатып калган мәчет үз урынында. Күңел шунда ымсына. Кайтырга кирәк! Юк, кайчан мондый җай чыга әле, кереп чыгарга кирәк. Уйларымнан аяклар мәчеткә таба атлый. «Бисмиллә»мне әйтеп эчкә узам. Ишек катында кизүдә торучы бабай:

– Әссәләмүгаләйкүм кызым, тагын бер кат, сумкаң бигрәк зур, нәрсә тутырдың? – дип каршы ала.

– Вәгаләйкүмсәлам, бабай, алтынчы классның бөтен гыйлемен тутырдым, – дип «гыйлем сумкасын» сәкегә утыртам.

– Укытучы икәнең йөзеңә чыккан, кызым, – дип елмая карт.

«Маңгаема язылмаган! Зирәк карт икән!» дигән уйларымны укыгандай:

– Кешенең эчендәгесе тышында, балам, аның өчен зур гыйлем кирәкми, – дип «чеметеп ала» бабай.

Әйе, алар әнә зур институтлар да бетермәгәннәр, зур-зур уку йортлары да тәмамламаганнар, тормыш дәресен яхшы үзләштергәннәр шул, дигән уйларымнан ил картлары өчен канәгатьлек кичереп, мәчеткә үтәм.

Икенде намазына да күп калмаган. Монда кергәч, тәһарәт яңартмыйча булмас, тәһарәтсез йөрелми инде дә, көнлек тузанны чистартырга кирәк, дип тәһарәтханәгә – астагы катка төшәм.

Тәһарәтханәне яңа гына ясап бетереп яталар. Бетон тузаны исе дә бетмәгән, идәнгә җәелгән плитәләрнең әр яңа икәне күренеп тора. Кергән кергән карап чыгыйм әле дип, түргә узам. Түр ягы раковиналар янында кемдер кайнаша. Сәлам бирмичә ярамас, матур түгел дип, сәлам бирәм:

– Әссәләмүгаләйкүм, абзый, Алла куәт бирсен!

Сәламемә, кулларын өстендәге эш халатына сөртеп, абзый башын күтәрә. Хатын-кыз булуымны аңлап, өстендәге тузанын да каккалап:

– Вәгаләйкүмсәлам, кызым, – дип җавап кайтара.

– Бигрәк саваплы эшкә алынгансың, бигрәк матур, боларның барысы да сез эшлисезме? – дип кызыксынам абзыйдан. Абзыем эшеннән аерылмыйча гына:

– Халык булыша кызым, халык. Эштән бушаганда килеп булышалар, – дип аз сүзләнә.

– Көне буе эшлисезме монда? – дип сорыйм кызыксынуымны яшермичә.

– Ястүгә азан әйтеп, намаз укытам да, кайтып китәм инде, – дип җавап кайтара. Мин һаман төшенә алмыйм.

– Ничек, сез азан да әйтәсезме? – дим.

– Азан да әйтергә туры килә, мәчетнең мулласы булгач, – дип ирен чите белән елмая абзый.

Ни өчен кергәнемне искә төшерергә теләп, тәһарәт алырга ашыгам. Абзыем шунда ук гаип була.

Зур якта – намаз залында, яшел чапан кигән, башына ак чалма ураган әле генә сөйләшкән абзый-мулла азан әйтергә әзерләнә. Кай арада өлгергән диген син.

– Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!...

Пәрдә белән бүленгән якка, намазга килгән хатын-кызлар янына килеп басам. Аяклар келәмгә бата. Кулларымны баглыйм һәм: «Иләһи ният кылдым, икенде намазын укымакка, оедым ошбу имамга», – дип эчтән генә кабатлыйм. Уйлар каядыр китмәкче була, тырышам – читкә җибәрмим. Нindидер рәхәтлек билеп ала. Бу рәхәтлектән күзләр ирексездән йомыла. Сәҗдәгә китәм: «Йә, Аллам, нинди бөексең!». Тез өсләренә кулымны куеп идәнгә утырып, ике якка сәлам бирәм. Рәхмәт хисләре арта. «Йә, Аллам, укыган намазымны кабул ит», – дип кулларым белән битемне сыпырам, учларымны чылаткан яшь тамчыларыннан рәхәт булып китә.

Узып барышлый, мәчеткә кереп чыгарга кирәк дигән җирдән күпме рәхәтлек алып кайтып була икән бит!

**Гөлфия Насыйбуллина,**
**Чаллы.**

# Беренче баскыч

Бер кеше шәих Фәрит янына килеп: “Миңа Аллаһы Тәгаләне ярату юлын күрсәт әле”, - дип эндәшә. “Әйт әле миңа: синең үз гомереңдә кемне дә булса сөйгәнең бармы?” - дип сорый Фәрит хәзрәт. “Мин дөньяви әйберләр белән кызыксынмыйм, дөнья белән бәйле бер әйберне дә сөяргә теләмим. Минем бер генә теләгем бар, ул да булса Аллаһны сөю”, - дип җавап кайтара әлеге кеше. “Юк, син барыбер уйлап кара әле. Бәлки кайчан да булса берәр хатынны яисә баланы, дустыңны сөйгәнең бардыр?” - дип сорый хәзрәт. “Мин бит инде әйттем. Минем беркемне дә сөйгәнем дә, яратканым да юк. Мин бит дин кешесе, шулай булгач, миңа Аллаһны сөю юлын күрсәт”, - ди теге кеше кабатлап. Бу җавапны ишеткән шәих Фәрит елый башлый: “Дөньяда кемне дә булса сөймичә торып, Аллаһны сөеп булмый. Бу бит дин юлының, башка тәрле әйткәндә, Аллаһны сөюнең беренче баскычы булып тора. Син исә, беренче баскычына басмаган хәлдә, миннән иң соңгы баскыч турында торыйсың. Бар кит, башта кемне дә булса сөй, соңыннан минем яныма килерсең”, - ди.

(Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин. “Бәхетлеләрнең серләре”.



**Фото интернеттан алынды).**


*Прайс-лист на изготовление печатных агитационных материалов по выборам Депутатов Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва 08.09.2019г. В ООО «Духовно-деловой центр «Ислам нуры» ИНН 1650076344*

| Наименование | | Тираж | |
|---|---|---|---|
| Формат | Листовка | 1000 | 5000 |
| А4 | 4+0 бум. 80 гр. ВХИ | 5,00 | 1,82 |
| А4 | 4+0 бум. 90 гр. мел | 5,70 | 2,30 |
| А3 | 4+0 бум. 80 гр. ВХИ | 6,00 | 2,80 |
| А3 | 4+0 бум. 90 гр. мел | 7,00 | 3,56 |

*ООО «Духовно-деловой центр «Ислам нуры» ИНН 1650076344*
*Цены указаны за печать в рублях за единицу. НДС не облагается. Стоимость продукции, не указанной в прайс-листе, рассчитывается отдельно. Прайс действителен с 01.07.19 г.*
*г. Набережные Челны, ул. Центральная, 72*
*Тел.: 8552-705-109*

*Прайс-лист на изготовление печатных агитационных материалов по выборам Депутатов Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва 08.09.2019г. В ООО «Агентство рекламы и полиграфии «Диамант» ИНН 1650124661*

| Наименование | | Тираж | |
|---|---|---|---|
| Формат | Плакат | 3000 | 5000 |
| А2 | 4+0 бум. 80 гр. ВХИ | 5,85 | 5,15 |
| А2 | 4+0 бум. 115 гр. мел | 7,30 | 6,50 |
| А3 | 4+0 бум. 115 гр. мел | 4,20 | 3,40 |
| А3 | 4+0 бум. 150 гр. мел | 4,75 | 4,00 |

*ООО «Агентство рекламы и полиграфии «Диамант» ИНН 1650124661*
*Цены указаны за печать в рублях за единицу, в т.ч. НДС 20%. Стоимость продукции, не указанной в прайс-листе, рассчитывается отдельно. Прайс действителен с 01.07.19 г.*
*г. Набережные Челны, ул. Центральная, 72*
*Тел.: 8552-705-145, e-mail: 705145@mail.ru*



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды: график буенча 25 июнь16 сәг. фактта 25 июнь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**